СОВЕТ
МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Улица Колхозная, дом 2,
село Матаки, 422473

Улица Колхозная, дом 2,
село Матаки, 422473

Тел.: (84375) 3-81-17, 8(9393940522), факс: (84375) 3-81-18, e-mail: Matak.Drz@tatar.ru,

**Матак авылы**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның "04" май №32/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану Тәртибенә үзгәрешләр керту турында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советының 02.06.2020 ел, № 57/3 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану Тәртибенә” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: 3

пунктның 2 абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1,3 абзацында, 11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)»сүзләре белән алыштырырга

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Матак авыл җирлеге башлыгы
Чүпрәле муниципаль районы
Татарстан Республикасы: В.И.Шумилов